СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

27.03.2023№ 31/5

На №_________от_____________

# КАРАР

## Тукай муниципаль районы Советының «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү хакында

Тукай муниципаль районы Советының «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча фикер алышуда Тукай муниципаль районы халкының катнашу хокукларын саклау максатыннан, Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 санлы нигезләмәгә таянып, муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Тукай муниципаль районы Советының «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.

1.1. Халык тыңлауларын үткәрү вакытын билгеләргә: 2023 елның 12 апрелендә 17.00 сәгатьтә, үткәрү урыны: Яр Чаллы ш., М.Җәлил пр., 46 й. (муниципаль район Советы утырышлар залы).

1.2. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар 2023 елның 10 апреленә кадәр почта аша җибәрелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46 йорт, 330 кабинет яисә факс буенча: (8552)701724.

2. Тукай муниципаль районы Советының «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча халык тыңлауларын уздыру тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны һәм Тукай муниципаль районы Советының «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проектын 2023 елның 29 мартыннан да соңга калмыйча, «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга һәм Тукай районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Түбәндәге составта оештыру комитетын төзергә:

- Камаев Фаил Мисбах улы – район Башлыгы,
- Сәхбиев Мансур Шакирҗан улы – бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт

буенча даими комиссия рәисе, Биклән авыл җирлеге Башлыгы,

- Гончарова Ольга Анатольевна – бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссия әгъзасы, Шилнәбаш авыл җирлеге Башлыгы,

- Хәбибуллин Айрат Рафак улы – район Башкарма комитеты Җитәкчесе;

- Камалова Айгөл Ринат кызы – район финанс-бюджет палатасының әйдәп баручы белгече.

4. Оештыру комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2022 ел өчен Тукай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев